# РӘСӘЙ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ХӨКҮМӘТЕ
# ЗАТКА БАЛАНЫ УЛЛЫККА (КЫЗЛЫККА) АЛЫРГА, ОПЕКАГА АЛЫРГА (ПОПЕЧИТЕЛЬЛЕК), ТӘРБИЯГӘ ЯКИ ПАТРОНАТ ГАИЛӘГӘ АЛЫРГА КОМАЧАУЛАУЧЫ АВЫРУЛАР ИСЕМЛЕГЕН РАСЛАУ ТУРЫНДА

**2013 елның 14 февраленнән**

**117-нче номерлы**

**КАРАР**

Рәсәй Федерациясенең Гаилә кодексы нигезендә Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте карар бирә:

1.Затка баланы улыкка (кызлыкка) алырга, опекага алырга (попечительлек), тәрбиягә яки патронат гаиләгә алырга комачаулаучы беркетелгән авырулар исемлеген расларга.

Беркетелгән авырулар исемлеге шулай гаилә рәвешендәге балалар йортларында тәрбия эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларга да тарала дип билгеләргә.

2. Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте “Затка баланы улыкка алырга, опекага алырга (попечительлек), тәрбиягә алырга комачаулаучы авырулар исемлеген раслау турында” 1996 елның 1 маеннан 542-нче номерлы карарын (Рәсәй Федерациясенең канунчылык җыелмасы, 1996, № 19, 2304 маддә);

Рәсәй Федерациясе Хөкүмәте "Гаилә рәвешендәге балалар йорты турында" 2001 елның 19 мартыннан 195-нче номерлы карарының 2-нче пунктын (Рәсәй Федерациясенең кануннар җыелышы, 2001, № 13, 1251 маддә)

үз көчләрен югалткан дип танырга;

Рәсәй Федерациясе

Хөкүмәте Рәисе

Д. МЕДВЕДЕВ

2013 елның 14 февраленнән
117-нче номерлы
Рәсәй Федерациясе
Хөкүмәте карары белән
расланды

**ЗАТКА БАЛАНЫ УЛЛЫККА (КЫЗЛЫККА) АЛЫРГА, ОПЕКАГА АЛЫРГА (ПОПЕЧИТЕЛЬЛЕК), ТӘРБИЯГӘ ЯКИ ПАТРОНАТ ГАИЛӘГӘ АЛЫРГА КОМАЧАУЛАУЧЫ АВЫРУЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

1. I һәм II төркем диспансер күзәтүендә булган затларның сулыш органнары туберкулезы.

2. Диспансер күзәтүе астыннан озак саклана торган ремиссия сәбәпле чыгуга кадәр йогышлы авырулар.

3. Тәннең теләсә кайсы җирендә барлыкка килгән III һәм IV стадиядәге яман шешләр, шулай ук радикаль дәвалау үтмәгән тәннең теләсә кайсы җирендә барлыкка килгән I һәм II стадиядәге яман шешләр.

4. Диспансер күзәтүендә булган психик какшаулар һәм үз-үзеңне тоту какшаулары.

5. Наркомания, токсикомания, эчкечелек.

6. I төркем инвалидлыкка китергән авырулар һәм яралар.